КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 декабрь г.Казань № 1390

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм 2022 - 2030 елларга климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә дәүләт фәнни-техник сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 8 февралендәге 76 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм 2022 - 2030 елларга климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планын (алга таба - План) расларга.

2. Планның җаваплы башкаручылары булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

План чараларын гамәлгә ашыруны итәргә;

ел саен, хисап елыннан соң 1 мартка кадәр, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына План чараларын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүмат җибәрергә.

3. Оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмаларга План чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. План чараларын гамәлгә ашыру буенча дәүләт хакимиятенең координацияләүче башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгын билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 22 декабрь, 1390 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм 2022 - 2030 елларга климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планы

| Т/с | Җаваплы башкаручы, чараның исеме | Үтәү сроклары |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | |
| 1.1. | Татарстан Республикасы территориясендә чыгарып ташлаулар һәм парник газларын йоту күләмен инвентарьлаштыру | 2022 - 2030 еллар |
| 1.2. | Климат сәясәте мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасын декарбанлаштыру планнары буенча ведомствоара эшче төркем утырышларын үткәрү | Утырышлар үткәрелгән саен |
| 2. | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | |
| 2.1. | «2013 - 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» программасын тормышка ашыру | 2022 – 2023 еллар |
| 3. | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе | |
| 3.1. | «Карбон-Идел буе» карбон полигонын төзү һәм пульсацион үлчәү методлары белән климатик актив газлар агымын үлчәүне һәм җир өсте методлары белән углерод балансын оештыру (килешү буенча) | 2022 – 2025 еллар |
| 3.2. | Экологик үсеш һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен башкару (килешү буенча) | 2022 – 2025 еллар |
| 4. | «А.Н.Туполев ис. Казан милли тикшеренү техник университеты - КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе | |
| 4.1. | Экологик үсеш һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен башкару (килешү буенча) | 2022 – 2025 еллар |
| 5. | «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе | |
| 5.1. | Экологик үсеш һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен башкару (килешү буенча) | 2022 – 2025 еллар |

______________________________